Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ДЕКАБРЬ • 2022 • КАЗАН

12



Сергей АНДРИАНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

2023

Ел саен Яңа ел килә,
Гел яңалык көтәбез.
Яхшылыклар көтә-көтә
Һаман гомер итәбез.

Чыныгабыз авырлыкка,
Ә без соң нәрсә күргән?..
Әнә бездән алгы буын,
Интегеп, ачтан үлгән.

Сугышларда кырылганнар –
Алла каргаган мәллә?..
Юк, алар изге гамәлдә
Корбан булганнар мәндә.

Түзәбез барсына, шөкер,
Биргән вәгъдәләренә.
Ходай түзәргә кушкан бит
Адәм бәндәләренә.

Матурлыкка, гүзәллеккә
Күмелгән туган илем.
Шул бишектә гел тирбәлеп
Яшәрмен диган идем.

И туганым, Ватан изге,
Югалтмыйк, ул – бердәнбер!
Монда безгә әти-әни
Сулыш өргән, шуны бел!

Изге теләк, теләк кенә
Булып калмасын иде!
Гамәлләрдә муллык биреп,
Уңыш казансын иде!

2000 дә 23,
Кайчан соң бер яшәрбез?..
Моңа хәтле яшьнәмәдек,
Бәлки синдә яшьнәрбез?!



Ринат АБЗАЛОВ







ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Галимнәр ачыкланган: ир кеше көненә – 4000 сүз, ә хатын-кыз 8000 сүз әйтә икән. Ләкин моның сәбәбен аңлата алмаганнар...

Н. ГАЛЛӘМОВ

Әлмәт

– Монда нәрсә аңлашылмый соң? Ир кешегә бөтен нәрсәне дә ике тапкыр кабатларга кирәклеген теләсә кайсы хатын белә ич... – диде аксакалыбыз Шомбай, укучыбызның хатын укып чыккач.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Буйдак булу ялгызлар өчен түгел.

Ашыгу – бер нәрсә, ә өлгерү – икенче.

Хатынның фаразлары ирнең шиксез фактларыннан төгәлрәк.

Китаплар кешегә аның даһи фикерләренең бик үк яңа булмаганын исенә төшеркеп тору өчен кирәк.

Буш вакыты күп булган кешеләр аны вакыты бөтенләй булмаган кешеләр янында уздыралар.


Әгәр эш акчада түгел, диләр икән, димәк, сүз кеше акчасы турында бара.

Өметләргә өйләнәләр, вәгъдәләргә кияүгә чыгалар.

Без йөрәгебезне акчабызга караганда җиңелрәк тәкъдим итәбез.

(Киң фикер йөртүчеләр мәҗлесендә язып алынды.)

Вячеслав ШИЛОВ





Валерий ТАРАСЕНКО



ИЛДӘ БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН

Илдә ел башыннан бюджет акчаларын урлау белән бәйле 8 мең җинаять эшләнгән, ә алардан килгән зыян 16 миллиард сум тәшкил иткән. Бу, әлбәттә, бары тик рәсми рәвештә теркәлгән фактлар һәм суммалар. Ә күпме шомарып беткән ришвәт алу осталары коррупция статистикасына эләкми кала – моны күз алдына китерү дә кыен...

Ә безнең алдынгы Татарстан ничек? Елның беренче тугыз ае эчендә республикада 185 ришвәт алу очрагы теркәлгән. Коррупция буенча бу нәтиҗә Мәскәү, Ставрополь һәм Краснодар крайларыннан соң ил буенча дүртенче урында тора.

РЕКОРДЛАРНЫҢ РЕКОРДЫ

Күптән түгел Эчке эшләр министры В. Колокольцев Дәүләт Думасында чираттагы рекордсмен ришвәтче турында хәбәр итте. Бу юлы элеккеге энергетика министры урынбасары беренчелекне алган. Тикшерү эшләре тәмамланмау сәбәпле, аның исеме аталмаган, ләкин журналистлар аны барыбер казып чыгарганнар. 227 миллион сум белән элеккеге министр урынбасары А. Тихонов эләккән. Акчалар аңа дәүләт контрактлары төзегәндә ярдәм өчен арадашчылар ярдәмендә чит илләрдәге банклар аша тапшырылган.

ЯЛГАН ГРАНТ

Татарстанда Авыл хуҗалыгы кооперативы башлыгы, Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан технологик җиһазлар алу өчен бирелгән грантны шәхси максатларына тоткан. 20 миллион сумны ул, комиссиягә ялган документлар, килешенүләргә нигезләнгән бизнес-план биреп, конкурста откан. Хәзер мошенникны суд көтә.

ТАБЫШЛЫ СӘҮДӘ

Казанда призыв кампаниясе вакытында "ак билетлар" белән сәүдә итү буенча процесс башланып китте. Суд каршында Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнарының хәрби комиссариатлары медицина комиссияләре табибларына ришвәт тапшыруда гаепләнүче арадашчылар җавап тотты. Авыру буенча призывтан котылып калу өчен, 80 меңнән 260 мең сумга кадәр түләргә кирәк булган. Ак халатлар һәм "волонтёрлар" булмаган авыруларда 4,2 миллион сум ясаганнар.

ТАМОЖНЯ САТЫЛМЫЙ

Менә тагын бер очрак. Ашхабадтан Казанга очып килгән бер бәндә таможня аша законсыз рәвештә 10 мең доллар чыгарырга маташканда тоткарланган. Эшне мыштым гына йомып калдыру өчен, ул таможня хезмәткәренә шул ук акчаны төртергә тырышып караган. Хезмәткәр ришвәтне кабул итмәгән. Суд ришвәт төртүчегә 2,9 миллион сум штраф салган.

ТИЗЛӘТЕЛГӘН ЫСУЛ БЕЛӘН

Казанда ЮХИДИның өлкән инспекторы бер фирманың автомобильләрен учётка кую белән шөгыльләнгән. Гамәл "тизләтелгән ысул" белән – фотога төшерүсез һәм машинаны карамыйча алып барылган. Бер машина өчен ул 2 мең сум алып барган. Шулай итеп йөзләгән автомобиль теркәлгән, һәм 1,4 миллион сум җыелган. Инспекторны банк аша акча күчерү документларын өйрәнгәннән соң тапканнар. Акча ясау конвейерын оештыручыга аеруча зур күләмле ришвәт өчен статья яный.

ЮЛБАСАР ГАИШНИК

"Аеруча зур" коллегасыннан аермалы буларак, пат-руль хезмәтендә эшләүче полицейскийның эшчәнлеге андый ук киң колачлы булмаган. Ул Казан юлларында рульдә утыручы мигрантларны туктатып торган. Шәһәрдә яшәү кагыйдәләрен бозучылар өчен, "мәсьәләне хәл итү" мондый тәртип буенча эшләнгән: мигрантлар дусларына шалтырата, тегеләре – җавапка тартмаганга күрә акча тапшыру өчен полицейскийның таныш хатынына. Суммалар 4 меңнән 7 меңгә кадәр. Биш шундый очрак өчен гаишникны суд һәм "Вак ришвәтчелек" статьясы көтә.

КРИМИНАЛЬ ЙОМГАКЛАУ

Ә менә бөтенебезгә дә яхшы таныш хәл. Татарстанның Чистай, Алексеевский, Яңа Чишмә, Нурлат, Аксубай һәм Спас районнарында төзелеш эшләрен күзәтүче Госстройнадзорның Кама арты буенча башлыгын кулыннан тотканнар. Полиция хезмәткәрләре ул Алексеевский районының бер төбәгендә төзелгән корылмага йомгаклау кәгазе биргән өчен, "Приор" җәмгыяте вәкиленнән 250 мең сум кабул иткәндә пәйда булганнар. Бу вкыйга нәрсә белән йомгакланыр – моны суд хәл итәчәк.

ШОМА ҮТМӘГӘН

Бу елда Татарстанда ришвәт алган өчен биш муниципаль хезмәткәрне хөкем иткәннәр. Әтнә районында авыл җирлеге башлыгы бюджет акчаларына кул сузган. Чүпрәле районында төзелеш һәм архитектура буенча баш белгеч, ришвәт алып, кешеләргә торак төзү өчен субсидия оештырырга тәкъдим иткән. Шул ук сәбәп буенча Татарстан Экология министрлыгының территориаль идарәләренең берсендә эшләүче хезмәткәр хөкем ителгән. Лаеш районында элекке баш бухгалтер законсыз рәвештә торак алу өчен субсидия рәсмиләштерүдә эләккән. Ел эчендә Татарстан буенча коррупция белән бәйле җинаятьләр өчен 231 чиновник җавапка тартылган, 225 дисциплинар җәза алган.



Александр ШУЛЬПИНОВ

ТҮРӘЛӘРНЕҢ МӘКЕРЛЕ ЭШЛӘРЕН РИСВАЙ ИТҮЧЕ

Безнең якташыбыз Роман улы Гавриил Державин – татар морзалары нәселеннән. Ул бөек шагыйрь генә түгел, үз чорының күренекле идарәчеләреннән берсе булган. Анда шул вакытларга кирәк сирәк сыйфат ачылган: ришвәтчеләрне күрә алмаган, мошенникларны һәм аларны яклаучыларны сөймәгән, гомере буе шуларга каршы көрәшкән, закон сагында торган. Патшабикә Екатерина II белән дә танышмаган, ул үзенең статс-сәркатибе таләпләрен тыңламыйча, бармак аша карап эш иткән, вельможаларының һәм сөеклеләренең кыңгыр эшләрен күрмәмешкә салышкан.

"Әби патша" идарә иткәндә Державин ике мәртәбә губернатор булып торган: 1785 елда Олонецк губернасында (хәзерге Карелия) һәм 1786–1788 елларда Тамбов губернасында. Бу ике очракта да ул бу регионнарның хәлсезлеге ни сәбәптән икәнен белгән.

Әлеге губерналардагы үзенең бурычын ул законнарны үтәүдә күргән. Эш күрсәтү вельможаларның күренеклелегендә түгеллеген, көч-намус байлыгында һәм гаделлектә икәнен аңлаткан.

Державин өчен төп каршылык еллар буе электән килгән урыннардагы ришвәтчелек саналган. Мәсәлән, Каргопольда ул тирән тамыр җәйгән түрәләр ришвәтчелегенә тап булган – бөтен катламнарда һәм рангларда. Алар барысы да җинаятькә батканнар, хөкемгә тартылганнар, тикшерү эшләре белән шөгыльләнүне кемгәдер тапшыру да мөмкин булмаган хәлгә килгән. Судьяларны губерна шәһәреннән җибәрергә мәҗбүр карар кылынган...

Державин кода-кодагыйлыкны кискен тәнкыйтьләгән, бу исәптән, ул ачыктан ачык Олонец генерал-губернаторын Т. Тутолминны губерна түрәләренә әшнәлек оештыруын гаепләгән, аларның казна биналарын төзүдәге кыңгыр эшләрен ачкан. Тегесе "боларның тәртипсезлекләрен күрмәмешкә салынган, үзе үк закон бозган, кайчагында үзенең кулы белән төзәтелгән хөкем карарлары чыгарган".


Тамбовта Державин карак түрәләрнең дошманына әверелгән. Анда ул сәүдәгәр Матвей Бородинның мошенниклыгына юлыккан. Сәүдәгәр, генерал-губернатор И. Гудовичның абруена таянып, яһәмәсе ул "ышанычлы капиталист", казна акчалары белән күп миллионлы афёра эшләгән. Әлеге финанслау шәһәр төзелешенә билгеләнгән булган. Бигрәк тә зур гауга армияне азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсендә купкан – бу хәтта әлеге гамәлдә өзелү куркынычы тудырган. Монда Державин 32 ришвәт җинаяте ачкан. Губерна казнасыннан 400 меңгә якын акча урланганлыгы расланган. Губернатор-шагыйрьне дошман итеп күрә алмаучылар да йоклап ятмаган. Нәтиҗәдә, аның өстеннән шикаять язып һәм яла ягып, суд аша эшеннән алдырганнар. Бары тик Потёмкинның ярдәме белән генә ул җәза алудан һәм сөргенгә җибәрелүдән котылып кала.

Көчләрнең тигез булмау аркасында "түрәләрнең явызлыкларын һәм кысуларын ачучы" Державин әлеге көрәштә оттыра. Башкала, Рәсәйдә ниләр барганын, ниләр кыланганнарын бик әйбәт белеп торган, ләкин күрмәмешкә, ишетмәмешкә салынган: хөкемгә тартылган казна караклары урынына башкалары киләчәген дә. "Гөнаһлы эш кылучылар гадәткә әйләнәләр дә, соңыннан гадәт закон була", – дип кисәткән Державин.

Әлбәттә, шагыйрьне әүлиягә тиңләргә кирәкми, гәрчә ул губернатор дәрәҗәсенә хәтле күтәрелсә дә. Ул шул заманның зур кешесе, катлаулы һәм каршылыклы шәхес, ләкин аның үз дигәнен төгәл үтәве, ихласлылыгы, законнарның үтәлешенә тугрылыгы хәзерге көндә дә хөрмәткә лаек.

Фәридә МОРТАЗИНА,
Г. Державин исемендәге Лаеш музее директоры.

В. БИБИШЕВ шаржы



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Игорь КИЙКО

Абау!

БЕЗГӘ ДӘ, СЕЗГӘ ДӘ...

Казанда "Юдино" депосының элеккеге башлыгының урынбасары хезмәткәрләренә премия язганда бик юмарт булган. Шул ук вакытта ул үзен дә кимсетмәгән. Түләүләрнең зур өлешен шәхсән үзенә кайтаруны таләп иткән. Шулай итеп, үткен урынбасар коллективтан 90 мең сум җыйган.

КОМПЬЮТЕРДАН... ДИПЛОМ

Тукай районының Әҗмәкәй авылы башкарма комитетында буш җитәкче урынбасары урыны барлыгы турында белгәч, анда яшәүче бер ханымның күңелендә идарәче булу теләге уянган. Аның бу урында таләп ителгән югары белеме булмаган. Белемне законлы рәвештә алу мөмкинлеге булмагач, ул компьютер ярдәмендә бер танышының дипломына үз исемен керткән. Санаулы минутлар эчендә ханым дипломлы юристка әверелгән һәм югары урынга менеп утырган. Ялган турында полициягә хәбәр итеп, яңа идарәчене элекке ире "саткан".

ТЫЮЛЫ СУ

Бөгелмә районының Ключевка авылында гомуми файдалануда булган ике буа кинәт кенә шәхси милеккә әйләнгән. Бу үзгәреш турында су янына куелган тыю билгеләре күргән экологлар хәбәр иткән. Сусаклагычлар урнашкан җир бер кеше хуҗалыгына карый икән. Активистлар дөреслекне суд аша кайтарырга планлаштыралар.

МӘЙДАН БӘХӘСЕ

«Арт-сити» торак комплексында яшәүчеләр фатирларына ия булды булуын, ләкин менә тимер атлары өчен урын табылмады. Комплексны төзегән "Унистрой" компаниясе йортлар янында 40 түләүсез һәм 300 түләүле урын бирергә тиеш булган, әмма бу планнар мәйданны чикләүче шлагбаум һәм 8 "Тукталыш тыела" билгесе урнаштыру белән чикләнгән. Мәсьәләне суд хәл итәргә тырыша, ә компания җирнең бәясе бик нык күтәрелде, дип аклана.

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Илгизәр ЗАРИПОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Игорь КИЙКО





•••

Безнең заманда акча эшләве бер дә кыен түгел, соңыннан аны үзеңнеке иту авыр.

•••

Хатын-кызлар әйтеме:
– Бай ирләр карт булмый.

•••

– Доктор, иртән торгач минем аркам авырта.
– Төш вакытында торыгыз.

•••

Әби маршрут автобусында:
– Улым, базар янында туктатырсың әле, яме?
– Базара нет, әбика!
– Ничек булмасын? Кичә бар иде бит...

•••

– Әни, туңдырма сосискига караганда файдалыракмы?
– Улым, хәзер сосискага караганда, тәмәке тарту да файдалырак!

•••

Икътисад институты. Имтихан вакыты. Студент сорый:
– Әйтегезче, сез туган көне бүген булганнарга ташлама ясыйсызмы?
Укытучы:
– Әлбәттә! Бернichә баллны алып ташлый алам!

•••

Дәваханәдә.
– Мин хирургка языла аламмы?
– Безнең хирург түләүле, 2000 сум.
– Әгәр түләүсезенә керсәм?
– Бер-ике ай буе көтәчәксез чиратыгызны.
– Әгәр чиратсыз керергә сөйләшенә алсам?
– Әлбәттә! 2000 не түлисез дә...

•••

"Диңгез бүләкләре" кибетенә кердем, ә анда – барысы да акчага...

Бөтен сорауга җавап

Александр БРЮХАНОВ

Караңгы урамда хулиганнар Фәйрушинның борынына биргәч, ул өенә кайту белән Интернетта борын темасына мәгълүмат эзли башлады. Һәм ничектер үзеннән-үзе Гогольнең "Борын" повестен укып чыкты...

Әти-әнисенең гомер буе җыйган илле меңен кая куярга микән дип баш ватып утырганда, Островскийның "Котырган акчалар"ын үзләштерде, аннан соң Достоевскийның "Идиот"ын, ә аннан соң "Ярлы кешеләр"нең очына чыкты...

Хатынының үгетләвенә карамыйча, балыкка җыенганда, төн эчендә Пушкинның "Балыкчы һәм балык турында әкият"ен укып чыкты һәм эчтәлеген хатынына сөйләде...

Ә хатыны ахирәте янына кунарга киткәч, йотлыгып граф Толстойның "Анна Каренина"сын укыды.

Улы белән дәресләр аркасында әйткәләшкәннән соң Тургеневның "Аталар һәм балалар" романын укып чыкты...

Эшендә хезмәт хакын тоткарлагач, Фәйрушин уйга батты — нидән башларга: Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?" романыннанмы, әллә Герценның "Кем гаепле?"сеннәнме? Әмма тиздән акчаны түләделәр, һәм ул Гончаровның "Обломов"ын сайларга булды...

Кыскасы, бер ел эчендә Фәйрушин укымышлы һәм зирәк кешегә әйләнде, һәм аңа нинди дә булса мөһим мәсьәләне хәл итәргә кирәк булганда, ул Интернетка чума һәм анда китап укый. Ә китапта бөтен сорауларга да җавап бар икән бит...

Людмила УЛАНОВА

ҮЗЕМ ГЕНӘ БЕЛӘМ

Яңа ел бәйрәмнәре вакытында минем йөзем бик йончый.

Күзләрем телевизор һәм монитор экранына текәлеп утырудан арый.

Котлаулар кабул итүдән, елмаюдан битләрем арый. Электрон почтадан котлау алганда алар хәтта җәелеп китә. Менә шундый замана хикмәте.

Төрле файдалы һәм зыянлы ризык чәйнәүдән авызым арып бетә.

Бәйрәмнәрне дөрес уздырмаганымнан берөзлексез маңгаем җыерылып тора.

Иягем барысыннан да ныграк арый. Ул бит яңа елда көчле, ихтыярлы булырга һәм мине тәрбияләү белән шөгыльләнә башларга йөкләмә ала. Өстәвенә – телевизор һәм мониторга текәлеп утыруны, ашауны киметүне һ. б.

Борын да бик арый. Анда бит томауның туктап торганы юк.

Бәйрәмнәр беткәч, әлбәттә, эшкә чыгам. "Йөзеңә ни булды?" – дип гаҗәпләнәләр иптәшләрем.

Ни булганын үзем генә беләм. Мин аны өйдә калдырып килдем. Аңа да ял кирәк бит.

• • •

Декабрьдә Гавай утрауларында урнашкан отельгә кулына чаңгы тоткан рус олигархы килеп керә.

– Әфәнде, – ди аңа отель хуҗасы, – безнең утрауда ел буе кар булмый. Чаңгы белән монда нишләмәкче буласыз?

– Нишләргә икәнен үзем беләм мин аның, – дип җавап бирә кунак, – әнә, аэропортта кар төялгән ике махсус самолёт тора.



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Алмаз ХӘМЗИН

КУШ ЯНЫНДА КЕМНӘР?

Грантны кемнәр ала?
Кем әшнә гарантка,
Казнага якыннарга,
Кода-кодагыйларга,
Төртә белүчеләргә,
Бергә эчүчеләргә.
Тиккә ник бирсеннәр
Гадел яшәүчеләргә?..
Бу бездә яшәүнең
Аерым сыйфаты:
Ничек алга китик,
Мал булә – эт заты...



Максим СМАГИН



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Михаил МИХАЙЛОВ

Белгеч

Мин өйләнмәгән кеше һәм бер мавыккан нәрсәм бар – бераз телевизорларның рәтен беләм. Үзем белән һәрвакыт лупа белән үрдәкборын йөртәм. Берзаман бер кат өстәрәк яшәүче ялгыз хатын үтенеч белән мөрәҗәгать итте:

– Телевизорым начар күрсәтә! Карап чыкмассыз микән?

Кердем, лупамны алдым һәм кабельне сантиметрлап тикшерә башладым. Һәм маташа торгач, антеннаның эчке чыбыгына тиеп торган кадакны күреп алдым. Үрдәкборынымны алам һәм кадакны суырып чыгарам.

– Сез тылсымчы, чып-чын белгеч! Телевизор сатып алганда кибеттә күрсәткәннән дә шәбрәк күрсәтә башлады! – диде чибәр күршем, мине кочаклап.

Өч көннән бер катка түбәнрәк яшәүче икенче ялгыз хатын килеп керде:

– Нигәдер телевизорым өстәге күршенеккән начаррак күрсәтә. Ул сез ярдәм иттегез, диде...

Керәм, лупамны алам һәм антенна кабелен тикшерәм. Теге тиеп торган кадакны табам. Үрдәкборын белән аны суырып чыгарам! Телевизорның сурәте шунда ук әйбәтләнде. Күрше хатын мине кочаклап алды:

– Бу бит могҗиза! Ниһаять, чын белгечне очраттым! – Ул инде ярты ел интеккән икән, кая гына мөрәҗәгать итмәгән! Шунысы кызганыч – ханым миңа ошарлык чибәр түгел...

Ниһаять, миңа язмыш елмайды. Күрше йортта яшәүче сылу гына хатын килеп керде. Шулай ук ирсез икән.

– Ярдәм итегез, – ди бу, – телевизорны көйләргә кирәк иде, кинәт кенә начар күрсәтә башлады, ә сезнең турыда яхшы сүзләр йөри.

Киләм, лупа алам, кадакны табам. Сәер нәрсә күрәм: теге ике хатында кадаклар тутык иде, ә моныкы – өр-яңа! Шигем белән бүлешеп тормадым, кадакны суырып чыгардым гына! Нәтиҗәсе дә озак көттермәде!

– Сез сихерче һәм тылсымчы! Сезгә күптән күз салган идем инде, ә мондый белгечләрне, гомумән, очратканым булмады! Сезне кочакларга мөмкинме? – дип сорады хатын.

Мин дә аны кочып алдым. Тагын шуны әйтим, тиздән өйләнешергә җыенабыз. Тик лупа белән үрдәкборынны еракка куймадым. Сөйләнеп-мактанып йөрүчеләр күп хәзер, ә минем кебек белгечләрне бармак белән санарга була...



Илья КРИШТУЛ

Бәйрәм аша – кара-каршы

Руслан – Мәскәүдә туып-үскән кеше, һәм моның белән ул чиксез горурлана иде. «Ятлар тутырды каланы!» дигән сүзне беренче булып аның борынгы бабасы Юрий Долгорукийның үзенә әйткән, имеш. Һәрхәлдә, гаилә риваятендә шулай сөйләнә иде. Мәскәүне ул биш бармагы кебек белә иде. Шуңа күрә ерак Себер шәһәрендә яшәүче хатын-кыз туганыннан телеграмма алгач, ул бик шатланды, бер атналык отпуск алды һәм юл күрсәткечләр алып, аны вокзалга каршы алырга китте. Өенә кайтып, гадәттәге гөмбә, җимешләр һәм кайнатмаларны кабул иткәч, ул рәхмәт әйтте һәм эре генә сорап куйды:

– Йә, нәрсә? Кремль, Кызыл мәйдан, Третьяковка, Пушкин музее...

– ГУМ, ЦУМ һәм яңа ачылган сәүдә үзәге, поездда аны бик мактадылар, – дип җавап бирде туганы. – Калганнарын, Ходайның рәхмәте, телевизордан күргәнем бар.

«Провинция, алардан нәрсә көтәсең инде, – дип уйлап куйды Руслан. – Рухи байлык, культура хәзинәләренә бернинди тартылыш юк, башларында кибет кенә...» Ә аңа, тәрбияле кеше буларак, болай диде:

– Бик шәп, Ә Мәскәүне машинадан карарбыз, барыбер бөкеләрдә торасы...

Бер елдан соң Руслан үзе Себер каласына юл тотты. Туганы ире белән вокзалда каршы алдылар, өйләренә алып кайтып, Мәскәү күчтәначләрен кабул иттеләр һәм тәкәббер генә сорадылар:

– Йә, нәрсә? Драма театры, Мамин-Сибиряк музее, зоопарк...

– Чын Себер мунчасы, кедр чикләвегендә төнәтелгән аракы һәм сезнең төнге клубларыгыз, аларны поездда бик мактадылар, – диде җавап итеп Руслан. – Ә калганын Интернетта күргәнем бар.

«Мәскәү инде, нишлисең бит... – дип уйлап куйды туганы. – Рухи байлыкка бернинди тартылыш юк, башларында күңел ачу гына...» Ире нәрсә уйлагандыр, анысы билгеле түгел, ә болай ул көр тавыш белән әйтеп салды:

– Бик яхшы, миңа да юынырга кирәк, үзем генә бара алмас идем. А Мамин-Сибиряк машина тәрәзәсеннән дә бик шәп күренә, ул янәшәдә генә.

Һәм хатынына мөрәҗәгать итеп, чын себерчә өстәп куйды:

– Жый әле безне.

Борынгы заманнарда Себер мужиклары тайгага ауга китәр алдыннан шулай әйтә торган булганнар. Вакыт узу белән бу сүзләрнең мәгънәсе үзгәргән. Атна буе бичара хатын ирен һәм Русланны төнге клубларда "жыеп" йөрде, һәм, ниһаять, жыеп бетергәч, инде Себер хатынына өйләнергә өлгергән Руслан аннан вәгъдә алды – бер елдан Мәскәүгә, отпуск буена. Дөрес, себерчә нык гәүдәле яшь хатын Русланга шелтәле караш ташлады.

Ә вокзалда хушлашканда Руслан махмырдан моңсу тавыш белән пышылдады:

– Мамин-Сибирякны караган булсак шәбрәк булыр иде...

– Мин дә гомер буе Кремльне күрергә хыялланам... – диде туганы, хәйләкәр елмаеп.

Һәм алар, тәрбияле кешеләргә хас гадәт буенча, суырышып үбештеләр.








Николай ВОРОНЦОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Илгизәр ЗАРИПОВ



ЖИЛГӘ ОЧЫРГАН

Томск өлкәсе администрациясе эшләре идарәчесе Анатолий Иванов еш кына «Газпром»нан вертолет алып торган. Өлкәдә абруе зур булгач, аның үтенечен кире какмаганнар. Рәсми кәгазьләр буенча, рейслар эш өчен бик кирәк булган. Чынлыкта исә керосинны юкка яндырганнар – очу аппараты түрә һәм аның хезмәттәшләре тарафыннан шәхси максатларда файдаланылган. Ике ел эчендә иптәшләре белән 4 миллион сумлык ягулыкны җилгә очырган. Ә менә күккә булган мәхәббәте өчен үзенә генә җавап бирергә туры киләчәк, чөнки хезмәт үтенечләрендә аның имзасы тора.

КАРТАЛАР АЛДАМЫЙ

Волгоград өлкәсенең Урюпинск шәһәрендә яшәүче ир-ат өлешчә мобилизация турындагы хәбәрләрдән бик дулкынланган. Язмышын төгәл белү өчен, ул тарологка барган. Хатын-кыз тылсымлы карталар ярдәмендә югары көчләр белән элемтәгә кергән һәм клиентны хәрби операциягә эләкмәячәгенә ышандырган. Ләкин хәрби комиссариатның бу хәлгә үз карашы булган – аңа повестка килгән. Ачудан ярсыган ир үзен алдаган күрәзәче хатынны кыйнап ташлаган. Тик таролог хаклы булып чыккан, кузгатылган эш аркасында сәфәр билгесез вакытка кичектерелгән.

КАРАК – ТӘМЛЕ ТАМАК

Краснодарда туңдырма карагын тотканнар. 40 яшьлек ир кибеткә эшкә урнашкан, суыткычтан туңдырма алып, аны эш урынында ашап утырган. Ай ярым урлашканнан соң, җитәкчелек туңдырманың даими рәвештә кимеп торганын сизгән һәм тәмле тамакны җинаять урынында тоткан. Бу вакыт эчендә ир кеше 120 данә туңдырма ашарга өлгергән.

УҢАЙ ТЕЛ

Яңа Зеландиядә түрәләр файдалана торган телнең юкка чыгуы мөмкин. Илдә дәүләт органнары халык белән тәкәбберлексез сөйләшергә, рәсми документларда канцеляризм һәм махсус сүзләр кулланмыйча аралашырга мәҗбүр итүче закон кабул ителгән. Закон авторлары фикеренчә, гади салым түләүчеләр өчен аңлаешлы тел түрәләрне яхшырак аңларга, катлаулы-бормалы язуларны бетерергә һәм демократияне ныгытырга ярдәм итәчәк.



Анатолий РАДИН





Валерий ТАРАСЕНКО

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Чирләшкәләр

Сәлимә апа авырып киткәч, врачка барырга булды. Моңарчы хастаханәләргә йөрергә яратмаганга күрә, ничек язылырга, кемгә барырга белмичә йөдәде. Ярый балалары ярдәм итте. Бигрәк җәфалы икән ул врачка эләгү. Язылучылар күплектән бер-ике атна көтәргә туры килде.

"Шул вакыт эчендә хәлем дә рәтләнә төште бугай, врачларны азапландырып йөрисе килми", – дип уйлап куйды ул. Алай да, балалары барырга кушкач, поликлиникага килде.

Коридорда халык алай күп түгел иде. Үзе шикелле олырак яшьтәге хатын янына утырды. Чиратны көткәндә кешеләр аралашырга ярата. Менә Сәлимә апа янындагы ханым да сөйләнеп китте:

– Көндезге стационарга барырга исәпләдем. Врачымнан язулар алырга кирәк.

– Ул көндезге стационарның ни файдасы бар соң? Биш көндә генә дәваланып буламы? – дип сүзгә кушылды бер яшьрәк хатын.

– Миңа биш көне дә җитә. Калганын түләүлегә барып дәваланып бетерәм. Безнең табибның язуы булса, шул җитә. – дип җавап кайтарды ханым. – Минем йөрмәгән врачларым калмады. Барысына барам. Тикшеренәм. Күбрәк түләүлеләргә барам. Алар ныграк белә.

Сәлимә апа аны кызганып куйды:

– Кыяфәтегезгә карап торганда, таза-сау кеше шикелле сез. Шулай инде, тыштан гына күреп әйтеп булмый шул кемдә нәрсә бар икәнен.

– Тфү, тфү, сез, нәрсә? – диде янындагы күршесе. – Минем бер җирем дә авыртмый! Аллага шөкер!

– Алай булгач, ник врачларга йөрисез соң? – дип, бөтенләй аптырады моңа Сәлимә апа.

– Ничек инде? Врачларга күренергә кирәк, авырта башлаганны көтмичә. Мин гомерем буе шулай, бөтен җиремне тикшертәм, шифаханәләрдә ятам, санаторийларга баргалыйм. Күптән түгел ютәл белән азапландым. Безнең врач әйтә, сезгә салкын тигән, ди. Мин аллергологка язу сорадым. Түләүлегә барып яхшылап тикшерендем.

– Шулай, нәрсә булып чыкты соң? – дип сорап куйды Сәлимә апа.

– Салкын тигән булып чыкты. Калганы барысы да яхшы иде.

– Шуны белер өчен акча туздырып йөрдегезме?

– Туздырса ни булган? Акчасы күптер. – диде коридордагы кешеләр. Бу сөйләшүне тыңлап утырганнар икән.

Сәлимә апа чираты җиткәнен көтеп тормыйча:

– Китәм мин, утырмыйм. Врачларны аптыратып йөрмим әле. Көчле авыру түгел. Дәваланырмын, – диде дә өенә кайтып китте.



Казакъ ядкәре

Казанның үзәгендә Казакъстанның беренче президенты Нурсолтан Назарбаев хөрмәтенә аталган урам бар. Дөрес, элек Эсперанто дип аталган урам исемен үзгәрткәндә нишләптер казанлыларның фикерен сорарга оныттылар, ләкин барыбер бу – казакъ һәм татар халыкларының тамырлары белән Алтын Урда заманнарына китүче мәдәни һәм тарихи элемтәдә торуларының ачык дәлиле.

Казакълар – бик аралашучан һәм уен-көлке сөюче халык. Шуны да онытмаска кирәк, күчмә халыкның холкына тормышка фәлсәфи караш хас. Ә бу үз-үзеңнән көлә белү, юмор, катлаулы әйберләрдә дә күңелле яклар күрә белүгә яхшы нигез булып тора. Менә казакъ фольклорында да Алдар-Көсе исемле персонаж бар. Ул гади халыкны яклап, байлардан һәм хакимнәрдән көлүче чая һәм кыю кеше. Акыннарның иҗаты – җыруларда да зәһәр әсәрләр аз түгел. Акыннарның җәмгыятьтәге урыны алар өчен "авторитетлар" булмауны күздә тоткан. Аларның сүзенә гади халык кына түгел, байлар да колак салган. Беркемнең дә акыннарның авызын томаларга хакы булмаган. Аларның бәйгеләре – айтыслар вакытында тамашачылар тәгәрәшеп көлгәннәр. Менә шундый дала демократиясе!

Әгәр якынрак вакытка күчсәк, 1956–1998 елларда казакъ һәм рус телләрендә чыгып килгән "Ара" ("Шмель") журналын искә алырга була. Анда ул заманның иң шәп карикатурачылары һәм юмор осталары эшләде.

Бүген казакъ юморы белән КВН командаларының чыгышларында һәм башка сәхнә жанрларында танышырга була. Һәм, әлбәттә, күпсанлы мәзәкләрдә. Аларда бүгенге катлаулы тормышка күңелле караш чагылыш таба.

Менә аларның кайберләре.

• Казакъстанның башкаласының исемен нигә үзгәрткәннәр? Казакълар – күчмә халык, алар бер шәһәрдә озак яши алмыйлар.

• Өч нәрсәне өзлексез карарга була: казакъларның латин алфавитына күчүләрен, Конституция алыштыруларын һәм башкалаларының исемен үзгәртүләрен.

• Казакъ пылавында өч ат көче булуы мөмкин.

• Россиянең Евровидениесенә таҗик хатынын җибәрүе бигрәк тә русларны түгел, ә казакъларны кимсеткән.

• – Нигә Казакъстан парламенты депутатлары шундый юан һәм калын муенлы? Ә Европа парламенты депутатлары зифа буйлы. Эш нәрсәдә?

– Конституцияләре шундый!

• Элекке заманда шундый закон булган: йоклаган һәм ашап утырган кешегә һөҗүм итмәскә. Шуңа күрә казакъларга беркем дә беркайчан да һөҗүм итмәгән.

• Мин Целиноградта тудым, балачагымны Акмолада уздырдым, аннан соң Астанада яшәдем, беркөнне Нур-Солтанда уяндым, аннары тагын Астанада. Йөртте генә мине язмыш...

• Казакъстанда президент сайлауларында башка кандидатларның исемнәрен бюллетеньдә генә күрәсең.

• Казакъ акыннары нәрсә күрәләр, шуның турында җырларга яраталар. Шуңа күрә иң мөһиме – акын белән бергә мунча кермәскә.

• Әгәр дә бөтен казакълар Россиядән китеп бетсә, Мәскәүнең суши-барларында япон менеджерларын кем уйнар икән?


• Метрода казакълар төркемен турникет белән сугышкан өчен тоткарлаганнар. Сәбәбен алар: "Ул үзе беренче булып башлады!" – дип аңлатканнар.

• Гаҗәеп хәл: бер милли компаниянең оештыру структурасы генераль директорның нәсел агачын кабатлый икән.



А. ӘХМӘТОВ

– Бәрән зар беләнме? Әйе, кергән иде...



А. ОСТРОВСКИЙ

– Ирем хәзер зоопаркта эшли...

"Ара" ("Шмель") журналыннан рәсемнәр.



Рашат **НИЗАМИ**

ПАСПОРТ МӘРӘКӘСЕ


Август башларында микән, имтиханнарны уңышлы тапшырып, Казан дәүләт университетының тарих-филология бүлегенә укырга кердем мин. Укулар 1 сентябрьдә башланачак. Ә миңа, беләсезме, шуны олимпка күтәрелеп яшәр-укыр өчен паспорт юнәтергә кирәк. Иң элек авыл Советына кереп, нинди документлар кирәклеген белешәм. Иң читене һәм тиз генә кулдан килмәстәе – кечерәк кенә фотосурәтем кирәк булачак икән. Авылыбызда гына фотограф-фәлән юк, кәртечкәгә төшү өчен район үзәге Сабага тикле барырга кирәк. Транспорт юк диярлек, 30-40 чакрым араны урап кайтасы бар бит әле. Ә теге фото дигәнең ничә көннән соң әзер булачак – белгән юк. Вакыт бик тар. һәрхәлдә, минем үз вакытында паспортка ия булуым кыл өстендә эленеп тора!

Фантазиямне эшкә җигә торгач, ныклы бер карарга килдем бит, менәтерә. Бер тартмада – миннән дүрт яшькә иртәрәк туган бертуган абыем Җәүдәтнең кайдадыр укытучы таныклыгына төшкән әзер фотосы саклана иде. Күршетирәләрнең, бер-берегезгә тәмам охшагансыз, дигән сүзләре шушы адымга этәрде мине. Ә нигә әле әзер фотодан файдаланмаска?.. Документларымны төйнәдем дә, киттем район үзәгенә! Берни сизмәде анда эшләүче апалар, ике көннән соң кулыма шытырдап торган өр-яңа паспорт тоттырдылар.

Шулай итеп, университетка укырга дип аяк басканда, мин СССРның тулы хокуклы гражданины идем инде. Ышанасызмы, студент чагында биш ел буе "абыйлы" паспортым белән укыдым, яшәдем, тулай торакта кайнадым. Ул чакларда "Ялкын" журналы һәм "Яшь ленинчы" газетасында чыккан шигырь яисә хикәяләрем өчен, шул паспортны күрсәтеп, гонорар ала идем. Шик белдерүче күренмәде, фотосурәткә ныклап күз салучы булмагандыр, күрәсең.

Ни кызганыч, Җәүдәт абыемның гомере генә фаҗига белән тәмамланды. Хәрби очучы буларак, вертолеты белән Россия күгендә янып һәлак булды ул. Аңа нибары 24 яшь тирәсе иде... Сугыштан сул кулын югалтып кайткан фронтовик әтием бу югалтуны бик авыр кичерде, саташу зәхмәтенә дучар булып, бер мәлне хәтта психбольницада да ятып чыкты. Шөкер, тиз сәламәтләнде. Әниемнең исә төннәрен: "Улы-ы-ым..." – дип кычкырып-саташып елаганнары да гел хәтердә әле.

Исемә төштеме, абыемның паспорттагы теге тыйнак кына елмаюлы сурәте күз алдыма килеп баса да, ирексездән сагышка биреләм. Бер нәрсә юата мине: Җәүдәт абыемның тормыш юлы, романтик хыяллары, мәхәббәте һәм... фаҗигасенә нигезләнеп, "Кызыл кар яугач..." дигән әдәби повесть яза алдым мин. Рухы шат булсын, дидем.



Вячеслав БИБИШЕВ, 1998 ел.



Виталий ФЕОКТИСТОВ, 2003 ел.



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Телефон шалтырый. Трубкада бик ягымлы хатын-кыз тавышы:

– Хатын-кыз таксие чакырттыгызмы?

– Әйе.

– Ә ни өчен?

– Дөресен әйткәндә, бер рәхәтләнеп көләргә.

– Алайса чыгыгыз: килеп җитәр, хәзер туктар өчен урын сайлаячак.

• • •

– 40 яшь – кызык чор. Берәүләр әби булалар, икенчеләре – декретка чыгалар.

• • •

– Кадерлем, мин синең яшереп куйган акчаңны таптым, һәм шуның барысын да ахирәтләрем белән ресторанда бетердем.

– Борчылма, мин аны сиңа яңа тун алырга җыйган идем.

• • •

Счётчикларны салкын һәм кайнар суга тикшерү шуны күрсәтте: фатир хуҗалары кайнар судан файдаланып кына калмыйлар, аны яңадан сууткәргеч торбага җибәреп кулланалар икән.

• • •

Күршеләр ремонт ясарга керește. Алар хәтта обойларын да перфоратор белән ябыштыралар бугай диган уй кила.

• • •

– Алё! Идарә компаниясеме? Мин сезгә өченче мәртәбә шалтыратам инде – минем фатирда түшәмнән су ага!

– Чөнки тышта яңгыр ява, шуңа да башыгыз җитмиме?

• • •

Генерал гаскәрдәге туклану хәлен инспекцияли.

– Әйбәт ашаталармы?

– Так точно, кала да әле.

– Калганын кая куясыз?

– Ашап бетерәбез, әле җитми дә!

• • •

– Син ничек өйләндең?

– Интернет аша.

– Танышулар сайтындамы?

– Юк, модем ватылды да, театрга бардым...

Вячеслав ШИЛОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Сергей АНДРИАНОВ





ҖАВАПЛЫКТАН КАЧМАКЧЫЛАР...

Кадерле "Чаян"! Бераүгә дә сер түгел, хәзер яңа төзелешләрне ничек кирәк шулай әвәләп сафка бастыралар, төзелеш материаллары да кайдан ничек эләктерелгән. Нәтиҗәдә яңа йортка күченүчеләр теләсә кайсы җирдән җил өреп торган фатирга керергә мәҗбүр булалар, диварлары аша шау-шу ишетелеп тора, кыек-мыек стеналы, түшәмле һәм тәрәзәле бүлмәләр...

Барлык шушы "уңайлыкларга", Илһам Шакиров проспектындагы 11 нче а йортына тагын бер бәла өстәлде – өйгә кергән су краннардан гына түгел, торбалардан ага башлады. Яңгырлар яуганда балкон тәрәзәләреннән дә, күп очракта кайсыдыр ки торба шартлагач – бөтен йорт буенча да. Су басымын үлчәп торган редукторларның сыйфатсыз булуы сәбәпле, алар эштән чыга – кайнар су тама башлый, кран ватыла. Йортыбызга күчүгә бер ел үтмәде, инде бөтен җирдә стеналардан юеш бәреп чыкты һәм күгәрекләр барлыкка килде. Ә бит югыйсә фатирлар бик күп елларга ипотекага алынган.

Идарә компаниясе эштән чыккан бар нәрсәләрне үзебезнең исәптән алыштырырга тәкъдим итә: әгәр бушка эшләтүне таләп итсәгез, яңасын куячаклар, ләкин анысы да начар сыйфатлы булачак, диләр. Ә төзүче идарә – "Ак Барс Строй", яшәүчеләрнең үтенеченә игътибар итми, күрәсең, абруе төшкәнлектән судан коры чыкмакчы була...

"Салават Күпере" ТКсының 11 а йортында яшәүчеләр.

СЕЛКЕНМӘС КОЙМА

Кадерле "Чаян" Дөньяда шундый төзелешләр бар, мәсәлән, Стоунхенд, египет пирамидалары һәм бөек кытай стеналары. Алар үзләренең ныклыгы белән дан тоталар, вакытка да, табигый афәтләргә дә, кеше йогынтысына да бирешмиләр.

Андый корылмалар бездә дә бар. Мәсәлән, безнең Октябрьский бистәсендә.

130 метр озынлыгындагы һәм 4 метр биеклектәге койма вакытка да, законга да буйсынмый. Күп еллар буе без бу койманы сүтү өчен судта да көрәштек. Аның артына М. Ш. дигән байның кучемсез милке яшерелгән һәм ул Иделгә туры чыгу юлын бездән бүлеп тора. Үткән ел дөреслек җиңде дип уйладык, ләкин алай булып чыкмады – койма кабат калыкты. Элекке хуҗа теге дөньяга китсә дә, аның урынына улы калды, ә суд хөкеменең моңа бернинди катнашы юк икән. Менә хәзер уйлыйбыз – безгә нишләргә кирәк?..

Октябрьский бистәсендә яшәүчеләр.



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Әхмәт Ерикәй 1902 елда Башкортстанның Өлкенде авылында крестьян гаиләсендә туа. Бала чагыннан ук күп укый, поэзия белән кызыксына, рус телен ярыйсы үзләштерә. 15 яшендә аның матбугат битләрендә беренче шигырьләре күренә башлый. 1927 елда Әхмәт Ерикәй Мәскәүгә килә һәм Дәүләт журналистика институтына укырга керә. Студентлык чорында төрле газета-журналларга язышa, «Эшче» газетасы редакциясендә җаваплы сәркатип һәм редактор урынбасары вазыйфаларын үти.

1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театры студиясе ачылганнан соң, студиянең әдәби бүлек мөдире Муса Җәлил белән берраттан, Ә. Ерикәй дә татар телендә либреттолар һәм җырлар язу эшенә керешә. 1935–1941 елларда Ә. Ерикәй озак еллар буе халык арасында яратып җырланган «Җәйнең аяз таңнарында», «Гармун», «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Сипкелле диләр мине», «Тын бакчада», «Тагын хуш ис бөрки сиреньнәр», «Кәккүк», «Җырланмаган әле безнең җыр» кебек шигырьләр иҗат итә.

Бөек Ватан сугышы елларында Ә. Ерикәй фронт газетасында хезмәт итә, совет сугышчыларын фашизмга каршы көрәшкә өндәгән шигырьләр, очерклар һәм җырлар яза.

1945–50 елларда Татарстан Язучылар берлегенә җитәкчелек итә.

Сугыштан соңгы чорда шагыйрь поэмалар, лирик шигырьләр, мәсәлләр, дуртьюллыклар, җырлар, мәкаләләр яза, тәрҗемә итә. Ә. Ерикәйне үзенчәлекле шагыйрь итеп танытканы – кыска лирик шигырьләр һәм җырлар. Җыр итеп язылган шигырьләре халыкчан шигъри бизәкләр, тапкыр сүзләр, чорга хас иҗтимагый фикер-хис белән сугарылган. Аларның эчке аһәңе үзеннән-үзе көйне сорап тора, шуңа күрә композиторлар Әхмәт Ерикәй поэзиясенә еш мөрәҗәгать итәләр. 1982 елда шагыйрьнең җырлары аерым китапка тупланып, «Ике йөз җыр» исеме белән басылып чыга.

Әхмәт Ерикәй 1967 елның 15 сентябрендә Мәскәүдә вафат була.

СИРЕНЬНӘР ХУШ ИСЛӘР ТАРАТА

Җир йөзе яшәрә, шатлана май,
Сиреньнәр хуш исләр тарата.
Яшәрәм яз җиткәч, гөлсыман мин,
Күңелем яз ямен ярата.

Уйларны тибрәтә-тибрәтә җыр –
Өздереп Иделдә җырлыйлар.
Шомыртлар талларга: «Саумысыз!» – дип,
Хуш исле кульяулык болгыйлар.

Алдымда бормалы-бормалы юл,
Мин карыйм еракка-еракка.
Шул күзләр һаман да, һаман да бит
Тынгылык бирмиләр йөрәккә.

Елмая кәккүкле, тургайлы яз,
Күк күзләр дә, бәлки, елмаер.
Ай кебек бер генә елмайса да,
Язларның гомере озаер...

Ай кебек бер генә елмайса да,
Ачылыр дөньяның гөлләре;
Тагын да ямьләнер илемнең киң,
Гаҗәеп ягымлы җирләре...

ҖӘЙНЕҢ АЯЗ ТАҢНАРЫНДА

Җәйнең матур аяз таңнарында
Җанга рәхәт Идел ярларында,
Чык җемелди миләш яфрагында,
Елмаялар гөлләр болында.

Кошлар сайрый яшел куакларда
Яшәү матурлыгы турында.

Минем хәлләремне, минем хисне
Идел дулкыннары сөйли төсле.
Алкын Идел үзе тели төсле
Минем белән сердәш булырга.

Кошлар сайрый яшел куакларда
Яшәү матурлыгы турында.

Хәтерләтеп дулкын уйнауларын,
Уйный минем якты хыялларым;
Мәхәббәтем, дәртем, идеалларым
Күпер булыр барыр юлымда.

Кошлар сайрый яшел куакларда
Яшәү матурлыгы турында.



КАШТАН БЕЛӘН ҮРМӘЛЕ ГӨЛ

Яшь-яшь Каштан үсә. Буйга зифа,
Үскән саен төскә чибәрләнә.
Үрмәле Гөл аның тирәсендә
Сыгыла, сыргалана, көязләнә.

Сизелеп тора аның йөрәгенә
Гыйшык уты һич тә тынгы бирми.
Каштан белән очрашканнан бирле
Күзләренә аның йокы керми.

Ай-һай, наян икән Үрмәле Гөл,
Нинди оста сыргалана, үрелә,
Нинди йомшак, ничек сыйпый, назлый,
Сихерләрлек итеп көлә белә.

Каштанның да күңеле таштан түгел,
Иркәләгәнне соң кем яратмый?
Нигә Каштан үз бәхетеннән качсын?
Үрмәле Гөл гыйшкын кире какмый!

"Ах, яратам, иркәм, яратам!" – дип,
Үрмәле Гөл коча сөйгән ярын.
Юмалана, мактый, юхалана,
Иркен итеп җәя колачларын.

Сөйгәненең иңенә үрмәли ул,
Кочкан саен ныграк коча башлый.
Каштанга бу башта ләззәт бирә,
Ә аннан соң эче поша башлый.

Күп тә үтми, Гөлнең тозагында –
Сөю кочагында Каштан үлә.
"Яратам бит, иркәм, яратам!" – дип,
Үрмәле Гөл югарыга үрелә.

Бу мәсәлгә мораль рәвешендә,
Кисәтергә телим каштаннарны:
Нинди генә төстә күренсә дә,
Якын китермәгез куштаннарны!

ҖЫРЛАНМАГАН ӘЛЕ БЕЗНЕҢ ҖЫР

Хуш исләрен гөлләр сипкәндә,
Тәрәзәмне җилләр чирткәндә,
Карамадың нигә әйләнеп
Яннарымнан үтеп киткәндә?

Җылы язлар тик башланды гына,
Әле генә яшел киде кыр.
Әйтер сүзләр әле әйтелмәгән,
Җырланмаган әле безнең җыр.

Сине генә, бәхет йолдызым,
Хыялымда назлап йөртәм мин;
Аерылышу төне килмәсен,
Кавышу таңын, иркәм, көтәм мин.

Җылы язлар тик башланды гына,
Әле генә яшел киде кыр;
Әйтер сүзләр әле әйтелмәгән,
Җырланмаган әле безнең җыр.

БЕР ФИКЕРГӘ ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Минемчә, Варшава договоры таркатылган шикелле, НАТОны да бетерергә һәм... Россия–АКШ мөнәсәбәтләре бик тиз җайга салыначак – шуның белән вәссәлам!

Алмаз Хәмзин: Сине генә куясы бар икән Лавров урынына, Рашат!

Р. Н.: Теләсә кайсы ил президентының киңәшчеләре, куштаннары күбрәк булган саен, төрле якка борыла-борыла аның муены авырта башларга мөмкин.

А. Х.: Күп борылса муен, димәк, бу – уен.

Р. Н.: Кесә карагының кулын фокусчы кулы белән чагыштыру килешәме?

А. Х.: Вак мәсьәлә. Менә хәзер халыкның банктагы акчасыннан фокус күрсәтмичә дә коры калдыралар.

Р. Н.: Шагыйрь Зөлфәткә ул яшәгән йортка истәлек тактасы куелды. Ә менә Мөдәррис Әгъләмгә андый тактаны кайда куясы икән?

А. Х.: Аккош күлендәге урманга.

Р. Н.: Күпләрнең уе-фикере юк, без шулар өчен дә икеләтә дөресләп фикер әйтергә тиешбез.

А. Х.: Шаяртып әйтсәм ярыймы? Укол кадатмаска кирәк.

Р. Н.: Таллыкта сандугач оясына тап булдым. Бәрәкәт – аның түм-түгәрәк оясы гарәп хәрефләренең бормаларыннан үреп ясалган лабаса!

А. Х.: Ул көнне сәламәтлегең әйбәт идеме?..

Р. Н.: Бокста яисә катнаш көрәштә кыз-хатыннарның катнашуы – гайре табигый хәл. Алар бит барыннан да бигрәк бала табар өчен яратылган...

А. Х.: Теләсә кайда катнашмаса хатын-кыз була димени ул?..

Р. Н.: Дәрдмәндтән үрнәк алырга кирәк – әдәбиятта эз калдыру өчен бер китап та җитә!..

А. Х.: Менә син яшәп кара хәзер бер китап язып кына! Аягыңгы сузарсың...

Р. Н.: Кешеләрнең күз яше кайгы-хәсрәт нәтиҗәсендә түгел, суган тураган чакта гына тәгәрәп төшсен иде...

А. Х.: Ә ул хәзер ашыйсы килгән чакта да чыга башлады.

Р. Н.: Акыллы кеше зур үзгәрешләр буласын көтеп яши...

А. Х.: Үзгәрешләр булмаячагы көн кебек ачык, димәк, акыллылар да юләрләнеп бетәчәк.

Р. Н.: Ялгыш адымнар – атлаганда гына түгел, урындыкта (көчәйтебрәк әйтик әле), кәнәфидә утырган вакытта да ясалырга бик ихтимал.

А. Х.: Сессиядәгеләр турында әйтәсең бугай...

Р. Н.: Ялган белән дөреслек янәшә йөрергә дә мөмкин.

А. Х.: Бездә ялганнан башка дөреслек юк та шикелле түгелме соң?..

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

ТАМГАЛЫ-ТАМГАСЫЗЛАР

Элек малга һәм дә колга
Тамга салган түрәләр.
Бүген исә ку-ар-кодлар
Өләшеп көн күрәләр.

Тамгалы вә тамгасызга
Куйдылар безне бүлеп.
Тамгалылар йөри булыр
Тамгасызлардан көлеп.

Тамгасызлар әйтерсең лә
Мәдәниятсез – кыргый.
– Тамгаң юк икән – гафу ит,
Беркая кереп булмый!..

Тамгаң юк икән – тамгалы
Җәмгыятьтә урын тар.
Илдә шундый уен бара...
Белмим, кайсыбыз отар.

Тамгасызлар кавеменә
Аерды безне язмыш.
...Әҗәлең җитсә – һәркемгә
Җир тигез – ике карыш.

Хәмид ВӘЛИДИ

АПТЫРАШ...

Хатын французча "теттерә",
Улым инглизчә "сибә".
Кызым "вау-вау" гел немесчә.
Оныкларым – урысча.
Базардан кенәри алдым,
Утырып киңәшергә,
Татарча сөйләшергә.
Бер эт сатып алам әле,
Кеше юк... тиргәшергә,
Үзебезчә рәхәтләнеп,
Тәмләп бер үртәшергә.



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 12 (1925) декабрь 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.12.2022 ел.
Тираж – 2754 Заказ О-3482


Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Русча вариантагы сорау: Чернобурка белән песецның аермалыклары нәрсәдә?

2. Үз үсешенең коралы?

3. Беренче ягулыклы транспорт чарасы?

4. Кызлар кайчан өлгереп житә?

5. Өченче буын автомобиле нинди ул?

6. Интернетны алыштырырдай иң яхшы ысулларның берсе?

7. Гадәттә ирләр нинди хатыннарны кулларында йөртәләр?

ҖАВАПЛАР

1. Чернобурка – төлке, ә песец – килеп чыккан хәл. 2. Тырма. 3. Емеляның миче. 4. Аны аш бүлмәсенә ашарга түгел, ә ризык әзерләргә чакырганда. 5. Ике буын тарафыннан тупланган акчага алынган автомобиль. 6. Урамга чыккач, эскәмиядә утыручы әбиләрнең сиңа карата бәя бирүләре: эчеңне, жаныңны актарулары һәм артыңнан кем икәнеңне әйтеп, кычкырып калулары. 7. Муенга менеп утырмаучыларны.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.


Чайнворды чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 11 нче санында басылган чайнвордның тикшерү сүзе – **«КЕРИМ ӘЛЕ УРМАННАРГА»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. САФИН (Балык Бистәсе, Полянка ав.),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тиганәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),

Җиңүчебез – Полянкадан **Рауль САФИН!**

Куян елы



Валерий ТАРАСЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Александр АЛЁШИН



Герман ОГОРОДНИКОВ

